КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 июнь г.Казань № 533

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 323 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 29 май, 340 нчы; 2009 ел, 2 февраль, 56 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2010 ел, 30 декабрь, 1156 нчы; 2011 ел, 4 ноябрь, 918 нче; 2013 ел, 30 сентябрь, 696 нчы; 2013 ел, 16 декабрь, 995 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 21 нче; 2014 ел, 31 гыйнвар, 52 нче; 2015 ел, 26 февраль, 116 нчы; 2016 ел, 19 май, 323 нче; 2016 ел, 3 сентябрь, 613 нче; 2018 ел, 14 апрель, 245 нче; 2019 ел, 7 май, 383 нче; 2019 ел, 12 сентябрь, 821 нче, 2021 ел, 31 май, 396 нчы, 2021 ел, 29 октябрь, 1020 нче, 2022 ел, 22 февраль, 155 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. әлеге Нигезләмәнең 3.1 һәм 3.2 пунктлары нигезендә Министрлык түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасының бюджет системасын һәм бюджетара мөнәсәбәтләрен камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли һәм чараларын гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый үсеш фаразларын озак сроклы, уртача сроклы һәм кыска сроклы перспективаларга эшләүдә билгеләнгән тәртиптә катнаша;

озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразы проектын (бюджет фаразына үзгәрешләр проекты) эшли;

икътисадны финанс яктан савыктыру һәм структур үзгәртеп кору, үзебезнең товар җитештерүчеләрнең, эшләр башкаручыларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең мәнфәгатьләрен яклау һәм булышу чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

эре салым түләүчеләрнең түләүләренә мониторинг үткәрә;

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын әзерләүдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә аларны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауны тәэмин итә;

Татарстан Республикасында инвестиция сәясәтен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар эшли, республика инвестиция программаларын эшләүдә һәм финанслауда катнаша;

Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар проектларын эшләүдә билгеләнгән тәртиптә катнаша;

үз компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча норматив хокукый актлар эшли һәм билгеләнгән тәртиптә кабул итә;

дәүләт акчаларыннан нәтиҗәле файдалану турында тәкъдимнәр эшләү буенча икътисадый юнәлештәге фәнни-тикшеренү оешмалары белән хезмәттәшлек итә;

үз территориаль органнарын мәгълүматлаштыру өлкәсендә бердәм сәясәт уздыруны тәэмин итә;

Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзи һәм аны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшыра;

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты фаразын эшли;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы бюджетын үти, Татарстан Республикасы бюджеты һәм Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты үтәлеше турында хисаплар төзи;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше турында хисап тапшыра;

Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасын төзи һәм алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты проектын төзү һәм Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше өлкәсендә методик җитәкчелек итә;

законнарда каралган очракларда Татарстан Республикасы бюджеты, шулай ук җирле бюджетлар үтәлешен беренчел һәм аннан соң тикшереп тора;

финанс-бюджет өлкәсендә эчке дәүләт финанс контролен гамәлгә ашыра;

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору вәкаләтләрен гамәлгә ашыру кысаларында шикаятьләр, планлаштырылган һәм планнан тыш тикшерүләр, алар буенча кабул ителгән карарлар һәм бирелгән күрсәтмәләр реестрын алып бара;

Татарстан Республикасы дәүләт чыгымнары структурасын камилләштерүгә юнәлдерелгән тәкъдимнәр әзерли һәм чараларны гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары системасын һәм аларның структурасын камилләштерү турындагы тәкъдимнәрне эшләүдә катнаша; Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары, аларның территориаль органнары аппаратлары хезмәткәрләренең иң чик саны һәм әлеге органнар аппаратларын тотуга ассигнованиеләр күләме турындагы тәкъдимнәрне әзерли; бюджет учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү системасын камилләштерү турындагы тәкъдимнәрне әзерләүдә катнаша;

бюджет планлаштыруы өлкәсендә бюджет чыгымнарының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән методологик җитәкчелекне гамәлгә ашыра;

салым сәясәтен камилләштерү, салым законнарын үстерү турындагы тәкъдимнәрне эшләүдә катнаша;

төбәк салымнары һәм җыемнары турында Татарстан Республикасы законнарын куллану мәсьәләләре буенча аңлатмалар бирә;

оператив идарә хокукында Министрлыкка беркетелгән дәүләт мөлкәте белән билгеләнгән тәртиптә идарә итүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының дәүләт бурычы белән идарә итү, шул исәптән аның структурасын камилләштерү һәм аңа хезмәт күрсәтү чыгымнарын оптимальләштерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр кертә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасының дәүләт эчке акча алулар программасын, Татарстан Республикасы дәүләт займнарын чыгару һәм урнаштыру шартларын эшли;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасының дәүләт тышкы акча алулар программасын эшли;

бюджет законнарында каралган очракларда Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасының эчке дәүләт акча алуларын гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча Татарстан Республикасының дәүләт гарантияләрен бирү программасын эшли;

Татарстан Республикасының Дәүләт бурыч китабын алып бара;

муниципаль берәмлекләрнең муниципаль бурыч китапларын алып баручы органнар тарафыннан тапшырыла торган муниципаль берәмлекләрнең тиешле муниципаль бурыч китапларында чагылдырылган бурыч йөкләмәләре турында мәгълүматны исәпкә ала;

Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләре реестрын алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты үтәлешенең касса планын төзи һәм алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре чыганаклары реестрын төзи һәм алып бара;

Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән расланган чаралар лимиты чикләрендә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә бюджет кредитлары бирүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрнең, бүлүчеләрнең һәм алучыларның җыелма реестрын алып бара һәм эшчәнлекләре Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган бюджет учреждениеләрен теркәүне гамәлгә ашыра$

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты йөкләмәсе буенча халыкара финанс оешмалары белән хезмәттәшлек итә, алар белән финанс сәясәте һәм кредит килешүләре төзү мәсьәләләре буенча билгеләнгән тәртиптә сөйләшүләр һәм консультацияләр үткәрә;

финанс, кредит һәм валюта мөнәсәбәтләре өлкәсендә хөкүмәтара һәм дәүләтара килешүләр проектларын әзерләүдә катнаша;

Татарстан Республикасында бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылыкн белән методологик җитәкчелегек буенча тәкъдимнәр әзерли һәм чараларны гамәлгә ашыра;

бюджет акчаларын алучыларның, шулай ук бюджет кредитлары алучыларның финанс хәлен тикшерүләр үткәрә;

бюджет кредитын кире кайтару йөкләмәләре үтәлешен тәэмин итүдә бирелә торган җаваплылыкны үз өстенә алуның, банк гарантиясенең ышанычлылыгын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бәяләүне гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасының дәүләт гарантиясен биргәндә принципалның финанс хәлен анализлауны, тәэмин ителешнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын тикшерүне, шулай ук принципалның финанс хәлен мониторинглауны, Татарстан Республикасының дәүләт гарантиясен биргәннән соң бирелгән тәэмин ителешнең җитәрлек булуын, ышанычлылыгын һәм ликвидлыгын контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыра;

Татарстан Республикасында кыйммәтле кәгазьләр базарын үстерү турындагы тәкъдимнәрне эшләүдә катнаша;

бюджет инвестицияләреннән файдалану шартларын һәм нәтиҗәлелеген тикшерүне үткәрә;

Татарстан Республикасы территориясендә чит ил инвестицияләрен җәлеп итүнең, аларны урнаштыруның дәүләт сәясәтен эшләүдә катнаша;

Министрлыкны тотуда һәм Министрлыкка йөкләнгән вазыйфаларны гамәлгә ашыруда каралган Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүче һәм алучы функцияләрен башкара;

Министрлык хезмәткәрләренең һөнәри яңадан әзерләү һәм квалификацияләрен күтәрүне оештыра;

Татарстан Республикасы закон актларында каралган очракларда җирле үзидарә органнары тарафыннан тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тикшереп тора, шулай ук дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирле үзидарә органнарына тапшырылган финанс чараларыннан максатчан файдалануны тикшереп тора;

Татарстан Республикасы закон актларында каралган очракларда җирле үзидарә органнарына тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында язма күрсәтмәләр җибәрә, шулай ук ачыкланган хокук бозуларны бетерү һәм аларны кисәтү өчен кирәкле башка чаралар күрә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының закон актларында каралган очракларда һәм тәртиптә җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренә тапшырылган дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә

ашыруны туктату турында тәкъдимнәр һәи тиешле Татарстан Республикасы законы проектын кертә;

Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы һәм җирле үзидарә органнары арасында бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру һәм җирле бюджетларның салым һәм салым булмаган керемнәрен арттыру чаралары турында килешүләр әзерләүне һәм төзүне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә һәм шартларда тәэмин итә;

дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнарда билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә Татарстан Республикасы ихтыяҗларын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алулар өлкәсендә тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы функцияләрен башкара;

Министрлыкның мобилизацион әзерлеген һәм мобилизациясен оештыра һәм тәэмин итә, ведомство буйсынуындагы оешмалар мобилизацион әзерлек чараларын үткәрүне координацияли, тикшереп тора һәм тәэмин итә, шулай ук әлеге чараларны методик яктан тәэмин итә;

бюджет йөкләмәләре лимитлары, финанслау чыганаклары, кредит бурычлары булу, закупкаларның нәтиҗәлелеген раслау өлешендә Татарстан Республикасы дәүләт ихтыяҗлары, муниципаль ихтыяҗлар (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыруны килештерү буенча вәкаләтләр гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган килешү булганда), Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре, муниципаль бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары (муниципаль бюджет учреждениеләре ихтыяҗлары өчен заказлар урнаштыруны килештерү вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашыру мәсьәләләрен җайга сала торган килешү булганда) өчен заказлар урнаштыруны килештерү буенча вәкаләтле орган була;

эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләүче Татарстан Республикасында эшләмәүче гражданнарны иминләштерүче вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган Россия Федерациясендә хокук куллану мониторингын гамәлгә ашыру методикасы нигезендә Татарстан Республикасында хокук куллану мониторингын үз компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашыра;

гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау өчен Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә аның компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча телдән һәм язма рәвештә хокукый консультация рәвешендә гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә, социаль ярдәмгә һәм социаль яклауга мохтаҗ гражданнарга гаризалар, шикаятьләр, үтенечнамәләр һәм башка хокукый характердагы документлар төзү һәм граждан мәнфәгатьләрен судларда,

дәүләт һәм муниципаль органнарда, оешмаларда тәкъдим итү рәвешендә түләүсез юридик ярдәм күрсәтә;

«Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасын алып бара;

Татарстан Республикасы муниципаль районының, шәһәр округының финанс органы җитәкчесе вазыйфасын биләүгә кандидатларның Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы билгеләгән квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдә катнаша;

законнар нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В. Песошин